ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
НИЖНЕЧЕКУРСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ ДРОЖЖАНОВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

*422483, село Нижнее Чекурское*
*телефон: 33-1-34*

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЧҮПРӘЛЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ТҮБӘН ЧӘКЕ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

*422483, Түбән Чәке авылы*
*телефон: 33-1-34*

с.Нижнее Чекурское

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

22 июнь 2020 ел № 15

Йорт хайваннарын урамда йөртү өчен урыннар билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында " 06.10.2003 ел, № 131-ФЗ Федераль Закон, «Хайваннар белән җаваплы эш итү һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 27.12.2018 ел, № 489-ФЗ Федераль закон, авыл җирлеге Уставы нигезендә, Чүпрәле муниципаль районы Түбән Чәке авыл җирлеге башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1.Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Түбән Чәке авыл җирлеге территориясендә йорт хайваннарын урамда йөртү өчен түбәндәге урыннарны билгеләргә:

-хуҗасы милкендә яки кулланышта булган җир кишәрлекләре;

- бордникларда һәм аларның хуҗалары күзәтүе астында кешеләр күпләп җыелмаган авыл җирлеге территориясендәге буш урыннар, торак сектор артында урнашкан урыннар:

1) Кече Аксу авылының төньяк-көнбатыш өлешендә Мичурин урамыннан 50 метр;

2) Иске Чәке авылының көнбатыш өлешендә Мәктәп урамыннан 50 метр;

3) Түбән Чәке авылының төньяк өлешендә Юл урамыннан 50 метр ераклыкта.

2. Балалар һәм спорт мәйданчыкларында, парклар, скверлар, массакүләм ял итү урыннарында, балаларга белем бирү һәм дәвалау учреждениеләрендә, мәдәният объектларына якын территорияләрдә, кибетләрдә, хайваннар белән бергә бару өчен махсус объектлардан тыш, йорт хайваннарын ирекле йөртүне тыярга.

Әлеге пунктның гамәлдә булуы поводырь этләренә кагылмый.

3. Җирле үзидарә органы карары белән хайваннарны урамда йөртү өчен рөхсәт ителгән урыннардан читтә йөртүгә, юл куймаска.

4. Әлеге карар рәсми рәвештә басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

5.Әлеге карарны авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында һәм Чүпрәле муниципаль районының рәсми сайтында авыл җирлеге бүлегендә игълан итәргә.

6. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Татарстан республикасы
Чүпрәле муниципаль районы
Түбән Чәке авыл җирлеге башлыгы: О.Б.Албутов